



ISSN 0868-4545

# Сәләт күпере



# Май ае – Хәтер ае

*Май, май, май килә,*
*Җиргә язгы ай килә!..*

Дөрес, май ае язгы ай булып кына килми, ул Хәтер ае да булып килә.

Хәтер ае 9 нчы Май көне белән аеруча истәлекле. Быел исә истәлекленең дә истәлеклесе – Ватан сугышында илбасарларны җиңүгә 55 ел тула.

Сугыш! Аның коточкыч афәт икәнен, кадерле дускай, инде син дә бик яхшы аңлыйсыңдыр. Гаиләгә олы Кайгы булып килгән бәхетсезлекләр, газиз туганнарны югалту, хәрабәгә әйләнгән өйләр, авыл-калалар...


Сугыш! Ул беркемне дә аямый – олыны да, кечене дә...


9 нчы Май – тынычлык өчен яуда башларын салганнарны юксыну, сагыну, аларның якты рухлары алдында баш ию көне.


Дөнья һәрчак тыныч булсын, дибез. Һәр яңа көн куаныч-шатлык кына алып килсен, дибез. Без бит бу дөньяга бәхетле булып яшәр өчен килдек. Син дә, нәни дускай, әти-әниең дә, әби-бабаң да, эне-сеңелләрең белән абый-апаларың да, дусларың да, кыскасы, һәммәбез дә бу бәхеткә лаек ләбаса!

Сугыш безнең Бәхетебезгә тимәсен бер үк!

Хәтер ае шуны искәртә...







Рәссам Светлана ПРИВИНА

Ләбиб Лерон

# Нәни димәгез миңа

Нәни димәгез миңа.
Илләр турында уйлыйм,
Җирләр турында уйлыйм мин,
Гөлләр турында уйлыйм.


Нәни димәгез миңа,
Нәни димәгез.

Июньнең бер иртәсендә
Нигә ал таң атмаган?
«Көт. Кайтам», – дип киткән бабам
Ник сугыштан кайтмаган.

Нәни димәгез миңа,
Нәни димәгез.

Ишетәм мин кайлардадыр
Зар елыйлар нәниләр.
«Берүк сугыш булмасын», – дип,
Теләк тели әниләр.

Нәни димәгез миңа,
Нәни димәгез.
Шулар турында уйлыйм мин
Нәни димәгез.







***Ватан сугышы татар шагыйрьләрен, язучыларын да аямады. Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Абдулла Алиш, Нур Баян, Гадел Кутуй...***

***Гадел Кутуй.***

***Әйе, «Тапшырылмаган хатлар», «Рөстәм маҗаралары», «Сагыну» (нәсер) дигән атаклы әсәрләр иҗат иткән Гадел Кутуй да сугыш афәтеннән исән-сау кайта алмады.***

***Ошбу сәхифәбездә, кадерле укучыбыз, синең игътибарга Гадел Кутуйның (1903-1945) һәм аның улы, шулай ук мәшһүр шагыйрь Рөстәм Кутуйның шигырьләрен тәкъдим итәбез.***

***Укы, уйлан, күңелеңдә уй-хисләр дөрләсен...***



Гадел Кутуй

# Туган ил

И туган ил, и матур ил,
Калдың бездән еракта,
Калсаң да бездән еракта,
Күңелдә син һәрчакта.

Суың тәмле, кырың ямьле,
Шифалы һаваларың,
Сугышларда дан казанды
Синең батыр улларың.

Искә төшә җәйге таңнар...
Рәхәт иде ул чаклар,
Бүген дәле янадыр күк
Без кабызган учаклар.

Искә төшә бәйрәмнәрең,
Табыннарың, казларың,
Бер карауда гашыйк иткән
Зифа буйлы кызларың...

Искә төшә кышкы көннәр,
Җем-җем иткән карларың.
Һәр аш саен кул күтәреп
Дога кылган картларың.

И данлы ил, и шанлы ил,
Син минем туган илем,
Киткән чакта эчкән суың
Тәме авызда минем.

И туган ил, и матур ил,
Нур күмә калаларың,
Һәр иртә-кич сине, илем,
Сагына балаларың.

Безне озаткан сукмакларны
Капламасын үләннәр,
Яз кайтмасак, көз кайтырбыз,
Сез көтегез, сөйгәннәр!

1944, Хәрәкәттәге армия,
Берлин юлы.

*Рәссам Сергей АНДРИАНОВ*



# Рөстәм Кутуй

## Челлә

Тилмерә мескен бозау,
Бар дөнья уттай кызган.
– Кем мине бәйләп киткән?
Гаебем бармы икән?

Бау бәйләп каккан казык,
Йөрмәсен диеп азып.

Мөгри бозау: «Му да му!
Үлемемме әллә бу?»



## Урман иясе

Агач төбендә –
Урман иясе,
Кулында – кишер,
Куян диярсең...

Күзгә яшь килә,
Аптырап торам, –
Кайда чытырман,
Кайда карурман?

Чыжлый пычкылар,
Күмеп җир ямен...
Кайда чикләвек,
Кайда җиләгем?


Кайларга качыйм
Мотор шавыннан?
Җил булып җылый,
Сыкрый карурман.

Урман иясе
Утырган төпне
Бульдозер сөреп,
Таптатып үтте.


Башыннан сыйпап
Килә сөясем, –
Табыгыз качкан
Урман иясен!

Разил Вәлиев тәрҗемәсе.

# Минем




– Улым тизрәк үссен, – диеп,
Ясады әни салат.
Бик үк ошап бетмәсә дә,
Чөгендер ашыйм сайлап.




– Зоопаркка барган идек, –
Җәнлекләр күп – шаккаттым.
Бик дуслаштык елан белән –
Кунакка алып кайттым.




– Энекәшне вилсәпидтә
Өйрәттем мин йөрергә.
Энекәшем, сәпидеңә
Утырт әле мине дә.




– Кайсысына ярдәм кирәк,
Укол кирәк кайсына...
Безнең «доктор Айболит»
Дару бирер барсына.




– Сурәткә төшкәнче генә
Туп-туры карап торам.
Өебезне ялт иттердем –
Эшкә бик ярап торам.




– Артта өчпочмак күләгә,
Янда сары яктылык.
Этем жырлый, мин елыймын
«Нишләргә?» – дип аптырый

# Матур балачагым







– Келтер-келтер арбасы,
Энем, кая барасы?
– Әбигә суга барыйк,
Оңгайга чиләк алыйк.







– Чәч кисү һәм бөдрәләтү
Бездән генә калмастыр.
Оста чәчтарашларның
Кул-бармагы армастыр.




– Узышып камыр җәябез, –
Ярыш бик кызып китте.
Апам йоклаган арада
Камыр җәелеп бетте.





Эсфир Яһудин

# Карак кәҗә фәрман яза



Борын-борын заманда,
Борын озын заманда,
Карак кәҗә-командир,
Киеп бик әйбәт мундир
Фәрман яза казыкка:
Кирәк, диеп, үстерергә
Тик кәбестә азыкка.
Риза түгел песиләр,
Йөриләр сөрән салып:
«Рәхәт яшим дисәгез
Тотарга кирәк балык».
Тычканнар чыелдыйлар:
«Гомер буена Ходай
Ачка интекмәс өчен
Чәчәргә кушкан бодай».
Кәҗә сайлый кәбестә,
Ә тычканнар ярмасын.
Песиләр – балык инде,
Ә этләр ит калҗасын.
Бар да үзенчә мактый
Үзе яраткан ашны.
Болай эш бармый, диеп
Туктаталар талашны.
Һәркем үзенчә итә,
Таң белән эшкә китә.
Тамаклары тук булгач,
Йөри алар кикереп.
Үз-ара сату итәләр,
Әвеш-тәвеш китереп.

*Рәссам Илдар НӘФИЕВ*



Рәссам Фәрит Муллахмәт

*Кадерле дускай!*
*Журналның урта битен иплэп кенә алып, кара сызыклар буенча кисегез, сары сызыклар буенча бөкләгез дә, килеп чыккан кисәкләрне, бит саннарына карап, китап итеп җыегыз. Булгач-булгач, чын китап булсын — уртасын ике урыннан тегеп куегыз.*

©«Салават күпере» китапханәсе.




## *Черкиләр*

Көннән соң
Төн җылынып
Җәйләр җитте исә,
Без дә без килеп черкиләр
Колакларны кисә...

Без дә без, диләр, без дә
без,
Үзгәртми җыр-көйне.
...Күпме тыңлап
ишетмәдем
«Мин» дигән черкине.






**Нәкыйп Каштан** тумышы белән Чувашстан ягыннан. Бүгенге көндә республика клиник хастаханәсе табибы. Балалар өчен дә, өлкәннәр өчен дә шигырь-хикәяләр иҗат итә.



* * *

Чәчәк кенә өзгән кәҗә,
Салам түбәгә менгән –
Мөгезенә кояшны элгән.





## Су анасы байлыкларын барлый

Күлем тирән, казанлы.
Казанлы да сазанлы.
Җәеннәрем мыеклы,
Елык-елык койрыклы.
Табан балык алтынлы –
Айдан алган алтынны.
Бәртәсләрем көмешле –
Тәңкәләре килешле.
Алабугам энәле,
Үзем бирдем энәмне.
Кызыл канат – уйнагым.
Тәңкәләре уймагым.
Су өстендә маймычлар,
Чуртан килсә таймычлар.
Шыртлакалар төркеме,
Өркетерлек һәркемне.
Кәрәкәләр гаскәре,
Зөбәрҗәтем фәсләре.
Ә бакамы?!
Ә бака...
Чү, тукта!
Кояш калка!




Инде арба элдертә –
Йөгерепме йөгерә!
Бакир янә караса:
Гаҗәпләнеп ул кала –
Арбасы буш ләбаса.





**Земфира Илфат кызы Исрафилова**
Казандагы 411 нче балалар бакчасында татар студиясен җитәкли.
Әлеге китапчыктагы «Өч теләк» сценариен да ул әзерләде.



Рәссам Фәридә Зөлкарнәева

**Дускай!**
Журналның урта битен иплэп кенә алып, кара сызыклар буенча кис, сары сызыклар буенча бөклә дә, килеп чыккан кисәкләрне, бит саннарына карап, китап итеп җый. Булгач-булгач чын китап булсын — уртасын ике урыннан төпләп тә куй.

©«Салават күпере» китапханәсе.

Земфира Исрафилова



## Балаларның авыруын сәхнәви уеннар ярдәмендә савыктыру



Спектакль тәмам булгач, сурәткә төшсәң дә ярый.

Бүгенге көндә әүвәлге елларга караганда кешеләрнең психикасы җәрәхәтләнгән, имгәтелгән халәттә. Моның сәбәпләре дә билгеле: экологик һәм экономик проблемалар, бүгенге тормышның катмарлы агышы, мәгълүматларның бихисап күплеге. Болар, әлбәттә, балалар психикасына да зур йогынты ясый. Балалар бакчасына сәламәтлекләре бик нык какшаган сабыйларның килүе ешайганнан ешая. Күп ата-аналар матди мәсьәләгә аеруча игътибар итеп, балаларның хис-халәтләренә күз йомалар. Ә бит бу бала өчен матди җитешлеккә караганда бик мөһим. Мондый гаиләләрдә балаларның «нервынный» булулары гаҗәп түгел. Шуларны истә тотып, без балалар бакчасында сабыйларга карата җылы мөгамәлә, игътибар һәм ягымлы караш булдырырга тырышабыз.





**Су анасы:**
Су анасы мин, китер, кайда минем алтын тарак?
Бир! Бая көндез алып качты синең угълың карак!

**Малай:** Калтырыйм, куркам, инде мин кайда барыйм?

**Әни:** Мин сиңа күпме әйттем – тимә кеше әйберсенә.

**Малай:**
Мин дә шуннан бирле андый эшкә кыймый башладым,
«Йә иясе юк!» – дип, әйберләргә тими башладым.

*«Алтын балык» җыры яңгырый. Спектакль – уенда катнашучылар тамашачыларга башларын ияләр.*

**Тәмам.**

**Кыз:** «Су анасы» әкиятеннән!
**Алтын балык:** Бик дөрес! *(Елмаеп чыгып китә.)*
**Малай:** Аh, бәла! Малай тарак чәлдереп чаба.
**Су анасы:**
Качма, качма! Тукта, тукта, и карак!
Ник аласың син аны, – ул бит минем алтын тарак!

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Бүлмә матур итеп җиһазланган. Ятак. Өстәл. Өстәлдә: самавыр, чынаяк, тәлинкә. Милли ризыклар. Әни өстәл янында чәй эчеп утыра.*

Малай *(йөгереп керә)*: Әни, алтын тарак таптым.
Сусадым, ардым, әни, мин бик озак чаптым.

*Әни, курка-курка гына кулына тарагын ала. Малай чәй эчә дә йокларга ята. Тәрәзә шакыган тавыш ишетелә.*

**Әни:**
Ни кирәк?Кем бу?Кара төндә вакытсыз кем йөри?
Нәрсә бар соң төнлә берлән, и пычагым кергери?







Бу – зур Шатлык.

Балалар үзара дустанә, тәрбиячеләр белән якын мөгамәләдә булсын өчен төрле уен-чаралар («Кул һәм гәүдә хәрәкәте белән шигырь сөйлә», «Кем тавышы», «Серле кайтаваз» дигән уеннар аша сөйләм кагыйдәләрен үзләштерәләр) оештырабыз. Балалар бакчасында тәрбияләнүчеләрнең тормышын иҗади шатлык белән тулыландыру буенча сәхнәви-театраль эшләр белән дә шөгыльләнәбез. Балаларны төп хис халәтләр: кызыксыну, куаныч-сөенеч, гаҗәпләнү, уйчанлану, усаллык, курку, оялчанлык белән «таныштырабыз».

Театраль уеннарда балалар әсәр геройлары белән бергә көлә, алар белән бергә борчыла, кайгыра, «куркыныч» килгәндә хәвефләнеп җафалана.

Курчаклар ярдәмендә күнегүләр үткәрү, этюдлар эшләү спектакль-уенны башлауда зур роль уйный.



Ә бусы – Курку.

Балалар, үзләре дә сизмәстән, артистларга әвереләләр. Безнең (ягъни балалар белән) тарафтан («Курайчык», «Тылсымлы итек», «Мәче баласы», «Соңгы алма», «Шапшак малай» (К.Чуковский әкияте) әкиятләре бик күңелле итеп уздырылды.

Театраль уеннарда катнашу балаларның иҗади мөмкинлекләрен ачты: сөйләмнәре, сәнгати аралашулары активлашты. Бу хәтта иң оялчан балаларда да күзәтелде. Мәсәлән, Чернобыль афәтен туктатуда катнашкан бер кешенең малае нерв авыруы – тики белән авырый иде. Элек малай башын иеп йөри иде, иңнәре иелгән, карашы идәндә, беркайчан да үзенә дәшүченең күзләренә карамас, тавышы йомшак-пышылдавыклы, гап-гади генә сорауга да җавап бирә алмый иде. Малай, аралаша торгач, кыюланып, үзендә көч барын тоеп, төрле рольләр (Крокодил, «Сабын», Бүре...) башкарды.





## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Урман. Бүреләр учак янына тезелешеп утырган. Кәҗә белән Сарык алар янына килә.*

**Беренче бүре:** Ашыйбыз, бу икәвен тотабыз да...
**Икенче бүре:** Менә ничек ит таптык бит боткабызга!
**Сарык:** Кайгырмагыз, бездә ит күп! *(Бүре башын күрсәтә.)*
**Кәҗә:** Микикики! Микикики! капчыктагы бүре башы бит уники!
(Сарык та тиз аңлап ала бу алдашны,
Капчыктан ул алып килә шул ук башны.)
**Беренче бүре** *(куркып)*: Ашау уе качты.
**Икенче бүре:** Ничек кенә качыйк.
**Беренче бүре:** Туктагыз, мин тиз генә боткага су китерим. *(Китә.)*
**Икенче бүре:** Качты өлкән бүре! Ягез, мин тиз генә аны эзләп килим. *(Китә.)*
**Кәҗә белән Сарык:** Качтылар болар, әйдә шәпләп ботка белән сыйланыйк.

*Ботка ашыйлар да йокларга яталар. Кыз белән Малай керә.*

**Кыз:** Иртә берлән иртүк торып, таң аткач ук...
**Малай:** Тагын болар урман буйлап сәфәр итте.

*Татар халык көе яңгырый. Алтын балык килә.*

**Алтын балык:** Менә сезгә өченче табышмак:
Җәй көне, эссе һавада мин суда койнам, йөзәм;
Чәчрәтәм, уйныйм, чумам, башым белән суны сөзәм.



Яки, янә бер мисал: ананың соңлап туган баласы – кызчык. Бала бик еш чыгырдан чыга, киреләнә, тиктомалдан ярсый. Үз ишләре белән ул, гомумән, аралашмый иде. Сәхнә уеннарында уйнаганнан соң, аның үз-үзенә ышанычы артты, шигырьләр укый башлады. Хәтта җырлау сәләте дә ачылды.

**Земфира Исрафилова.**



# Өч теләк

*(Г.Тукайның «Шүрәле», «Кәҗә белән сарык» һәм «Су анасы» әкиятләре буенча)*

Ошбу спектакль-уенда уйнар өчен Малай белән Кызга, Былтыр-Җегеткә, Күбәләккә, Бал кортына, Кәҗә илә Сарыкка, Су анасына, Шүрәлегә, урман ияләренә һәм Алтын балыкка махсус киемнәр кирәк булачак.

**Җиһазлар:** уенчык чәй тәлинкәләре, самавыр, балта, бүрәнә.

**Бизәлеш:** 1-2 нче күренештә – урман (ясалма чыршылар, агач төпләре, чәчәкләр).

3 нче күренештә – бүлмә (татар халык стилендә җиһазлана).

**Техник җиһаз:** магнитофон.

## БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

*Уен башында магнитофоннан «Алтын балык» дигән җыр яңгырый. Малай белән кыз татар биюен биилəр, җырның кушымтасына кушылалар:*

*Алтын балык, алтын балык, алтын балык,*
*Уйный суда, уйный суда, алтынланып...*

*Янә татар халык көе яңгырый.*
*Сәхнәдә Алтын балык (кыз бала) пәйда була.*

**Алтын балык:** Сез чакырдыгыз, мин килдем.

**Малай белән Кыз:** Исәнме, Алтын балык.

**Малай:** Син шундый матур, ягымлы балык.

**Кыз:** Без синең акыллы икәнеңне дә, һәммә нәрсәне эшли алганыңны да беләбез.





**Урман иярәре:** Кычкырма син, тиз яхшылык берлән тыел! И җүләр! Кысканга былтыр, кычкыралармы быел!

*Шүрәле һәм урман иярәре китә.*
*Татар халык көе яңгырый. Алтын балык, Малай белән Кыз пәйда була.*

**Алтын балык:** Хәзер сезгә икенче табышмак-шигырь:

Китте болар. Бара, һаман бара, бара, –
Күренмидер күзләренә ак һәм кара.

**Малай:** «Кәҗә белән Сарык» әкияте.

**Алтын балык:** Әйе! *(Елмаеп чыгып китә.)*



Чын атым «Былтыр» минем...





**Алтын балык:** Рәхмәт. Мин сезнең өч теләгегезне үти алам.

**Кыз:** Безнең бик тә, бик тә татар халык шагыйре Габдулла Тукайның әкиятләренә сәяхәт кыласыбыз килә.

**Алтын балык:** Мин сезнең теләгегезне үтим, әмма шундый шарт белән: хәзер шигырь сөйлим, әгәр сез ул шигъри өзекнең кайсы әкияттән икәнен дөрес әйтсәгез, шул әкият дөньясында пәйда булачаксыз. Тыңлагыз:

Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – Кырлай диләр;
Җырлаганда көй өчен «тавыклары җырлай» диләр.

**Малай белән Кыз:** Бу «Шүрәле» әкиятеннән.

**Алтын балык:** Бик дөрес. (Ул шулай ди дә кинәт юкка чыга).

*Магнитофоннан урман шавы, кошлар сайраганы ишетелә. Күбәләкләр, бал кортлары «очып» килә. Татар халык көе яңгырый, күбәләкләр, бал кортлары биилəр.*



Әйт әле, Күбәләк...

**Беренче күбәләк:**
Ул авылның, – һич онытмыйм, – һәр ягы урман иде,
Ул болын, яшел үләннәр хәтфәдән юрган иде.
**Бал корты:**
Ак, кызыл, сап-сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр;
Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр.
**Икенче күбәләк:** Үпкәлиләр чәчкәләрне төрле төсле күбәләкләр килеп, киткән булып, тагын да шунда чүгәләп.
**Икенче бал корты:**
Бик куе булганга, монда җеп-пәриләр бар диләр,
Төрле албасты, убырлар, шүрәлеләр бар диләр.

*Бал кортлары белән күбәләкләр, куркышкан булып, очып китәләр. Кулына балта тоткан Җегет пәйда була.*

**Малай:**
Тиз барып җиткән Җегет, эшкә тотынган баргач ук,
Кисә башлаган утынын балта берлән тук та тук!



**Кыз:**
Тукта чү! Ямьсез тавышлы әллә нәрсә кычкыра.
Сискәнеп, безнең Җегет катып кала аягүрә.

*Малай белән Кыз чыгып китә. Шүрәле пәйда була.*

**Җегет:**
Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? Йә өрәкме, нәрсә бу?
Кот очарлык, бик килешсез, әллә нинди нәрсә бу!
Сиңа миннән ни кирәк?
**Шүрәле:**
Тик кытыкларга яралгандыр минем бармакларым;
Булгалыйдыр көлдереп адәм үтергән чакларым.
Кил әле, син дә бармакларыңны селкет, и
Яшь Җегет! Килче икәү уйныйк бераз кети-кети.
**Җегет:**
Яхшы, яхшы, сүз дә юктыр,
мин карышмый уйныймын.
Тик сине шартымга күнмәссең диеп
мин уйлыймын...
Шул агачны бергә-бергә ошбу арбага салыйк.
Бүрәнәнең бер очында бер әрчелгән ярыгы,
Шул җиреннән нык кына син тот,
и урман сарыгы!

**Шүрәле:** Бик авырта кулларым, дустым, зинһар җибәр... Ичмасам, әйтче, зинһар, мәрхәмәтсез! Кем син? Исмең кем синең?


**Җегет:** Әйтсәм, әйтим, син белеп кал: чын атым «Былтыр» минем. *(Китә.)*

*Урман ияләре килә.*

**Шүрәле:** ...Кысты, харап итте явыз «Былтыр» мине, аһ, үләм бит, бу бәладән кем килеп йолкыр мине?

## Әй, аккош...

– Әй, аккош, аккош,
Син нигә ак?
– Кыйгак, кыйгак, кыйгак,
Мин диңгез күбегендә тудым.
Мин шуңа ак. Шуңа ап-ак!





## Кикрикле гөмбә

Кәрҗин тотып кулыма
Урманга киттем кереп.
Абага арасыннан
Кычкыралар:
– Кикрикүк!
Бәтәч –
Әтәч!
Каян монда – урманда?!
Карасам: кикрикле
Әтәч гөмбәсе анда...




## Буш арба

Балаларга күңелле –
Арбага йөк төйиләр:
– Алма, хөрмә һәм чия
Сизмәстән әл-лә күпме!..
Әфлисун да өяләр.

Бакир йөкче:
Кызыгып
Арбага тиз җигелә.
Ә үзе-е, йөкне күреп:
– Авыр ич, – дип үрсенә
Һәм билкәе бөгелә.

Балалар күз кысышып,
Елмаешып, булышып –
Йөк азлап бушатыла.
Җиңеләя арба тиз
Бакир тартыр узышып.





## *Миңа биш яшь*

*Марсельгә*

Иртән торсам, әй гаҗәеп
Бәллүр савытта – биш алма;
Тәлинкәмдә – биш салма;
Өчпочмагымда – биш почмак;
Аны татлы карбыз кочмак.

Хәтта торт та биш катлы,
Һәм чәк-чәге бик татлы.

Гел биш тә биш,
Гел биш тә биш –

Нигә бу алай икән?!
Бүген нинди сер бар дисәм –
Мин зур үскәнмен икән.
Миңа бүген – биш яшь икән.
Биш яшь икән...











## *Кем төшенә ни керә?*

Тавык төшенә тары керә.
Сыер төшенә печән керә.
Бахбай төшенә солы керә.
Мәче төшенә тычкан керә.
Маэмай төшенә сөяк керә.
Куян төшенә кишер керә.

Малай төшенә ни керә?
Алма бакчасы керә.
Ә кыз төшенә, ни керә?
Анысын ул үзе генә белә!

Илгизәр Солтан

## Күктән ява

Күктән ява яңгырлар да,
Күктән ява карлар да.
Күктән ява йолдызлар да,
Күктән ява нурлар да.

Күктән тагын нәрсә ява –
Йә, йә, кем әйтә ала?
– Күктән тагын җырлар ява,
Дип елмайды Гөлнара.

Тургай җыры, торна җыры,
Кыр казларыныкы да.
...Тыңлап кына торган Ирек
Сүзгә кушылды шунда:

– Тагын нәрсәләр явамы?
Авыр түгел белүе.
Күрәсезме, безнең янга
Ява кояш көлүе.

## Матур җир

Безнең авыл бик матур –
Урман якын булганга.
Су буендагы талларга
Сандугачлар кунганга.

Безнең урам бик матур –
Өйләр якты булганга.
Һәр көн саен тәрәзләргә
Кояш нуры кунганга.

Безнең өй дә бик матур,
Матур ул – мин булганга.
Ә мин нигә матур соң? –
Матур җирдә туганга.

Тәрәзәне ачып шулай
Мин елмаеп торам да,
Йөгереп чыгам урамга –
Матур җирдә уйнарга.

*Рәссам Илдар НӘФИЕВ*





## Чишмә

Авыл уртасында чишмә ага,
Су эчәргә килгән балалар.
Улакларда сөенеп кер чайкыйлар,
Чыркылдаша, куана балалар.

Үтә чисталыгы, суының сафлыгы,
Йөрәкләргә үтеп керә салкынлыгы.
Авылыбыз күрке булып чишмә ага,
Сагынырсың, читкә генә китеп кара!

**Вәсилә Ильясова.**
Ютазы районы, Кече Урыссуы.




*Радик Муллахмәтов, 9 яшь.*
*Арча.*



*Гүзәл Ибраһимова, 10 яшь.*
*Яшел Үзән.*



*Рания Вергазова, 10 яшь.*
*Яшел Үзән.*



*Рөстәм Сабиров, 10 яшь.*
*Балтач.*



Ришат Фәхретдинов, 7 яшь.
Ютазы.



Ләйсән Нигъмәтҗанова, 5 яшь.
Теләче.



Альмир Җиһаншин, 12 яшь.
Саба.



Ирек Шәймуллин, 8 яшь.
Арча.



Адель Сәлахов, 4 яшь.
Казан.



Гөлшат Миңнегалиева, 11 яшь.
Түбән Кама.

Канатлы талант

# Алмалар елмаюы



Бер табышмакны искә төшерик әле, дускай:

«Алма», – дисәң дә алалар,

Нәрсә соң бу, балалар?

Әлбәттә, җавабын беләсең инде син: «Алма», – дисең...

Әлеге биттәге рәсемнәргә карагач, синең әле алма ашыйсың да килеп киткәндер. Сурәтләрдәге алмалар нәкъ чын кебек бит, әйеме?!

Бу сурәт-натюрмортларның иясе – Наилә Рушан кызы Абзалиева. Ул һөнәре буенча рәссам түгел, әмма рәсем сәнгатенә чын күңелдән гашыйк. Кайчандыр Казан университетын тәмамлаган Наилә апаң соңгы берничә елда гына рәсем ясау белән чын-чынлап мавыга-шөгыльләнә башлаган.





Бер төркем язучылар һәм артистлар апрель аенда Пермь өлкәсендә әдәбият-сәнгать көннәре уздырдылар. Шунда катнашкан шагыйрә Илсөяр Иксанова кайта-кайтышлый ук «Салават күпере»нә бер кочак шигырьләр тапшырды. Аларны Октябрь районының Ишим мәктәбе укучылары иҗат иткән.

## Ялкау песи

Безнең песи ялкау диләр,
Ашый да уйный диләр.
Песиебез андый түгел,
Нигә шуны белмиләр.

Иртүк һич тора алмый шул,
Ята ул мырлап-гырлап.
Гырлый дип тә әйтеп булмый, –
Төш күреп ята җырлап.

**Марина Сафина.**

## Мин ясаган рәсем

Торам шулай зәңгәр күлнең
Ярларында мин басып,
Чупыр-чупыр йөзеп килә
Крокодил – су хуҗасы.

Уйный күбәләк белән
Шат күңелле арыслан.
Чалкан ятып, тәгәрәп,
Көлә ташбака аннан.

Ә аю уйга баткан,
Бөтерә йөнтәс кашын,
Куян табышмак әйткән,
Аптырап кашый башын.

Менә шулай бервакыт
Тынып калган барсы да.
Чөнки алар мин ясаган
Рәсемемдә – каршымда.

**Гөлчәчәк Сәхабиева.**

## Кошкайлар

Яз җитү белән кошкайлар
Безне сагынып кайталар.
Аларны да туган якка
Сагыну хисе тартадыр.

Без аларны бик көтәбез,
Матур оялар ясап;
Кошкайлар рәхмәт әйтә
Бик матур итеп сайрап.

**Эльвера Вазитова.**



*Рәссам Фәридә ЗӨЛКӘРНӘЙ*







«Салават күпере» + «Әлли-бәлли-бәү»: Ләбиб Лерон, Нурания Җамали, Ризәлә Фәттахова, Зиннур Хөснияр, Актырнак, Шаян һәм Наян белән.

«Салават күпере»нә 10 яшь тулуы хакында белдең син, шулай бит?! Инде телевидениедәге дустыбыз «Әлли-бәлли-бәү»гә дә шундый ук яшь тулганлыгыннан да хәбәрдарсыңдыр.

Менә шул, беркөнне уйлаштык-уйлаштык та, без – «Салават күпере» белән «Әлли-бәлли-бәү» – бергәләп «Карга боткасы» бәйрәме үткәрергә булдык. Әлеге рәсемнәрдә – шул бәйрәмнән күренешләр.

# Ә бездә бәйрәм әле...









*Фәрит Галимов фоторәсемнәре.*

Лилия Нигъмәтова Татарстан телевидениесендә озак еллар режиссер булып эшләде. Мактаулы хезмәте өчен ул Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән дәрәҗәле исемгә лаек булды. Лилия апа белән миңа да бер ара (мин «Салават күпере»нә нигез салышырга киткәнче) балалар өчен «Кырык тартма», «Кичке әкиятләр» («Әлли-бәлли-бәү» тапшыруы әүвәл шул исемдә чыга иде) тапшыруларын бергә эшләргә туры килде.

Лилия апа – «Салават күпере» журналының бик якын дусты. Синең игътибарга Лилия апа үзе иҗат иткән бишек җырын тәкъдим итәбез.

**Ләбиб Лерон**

Лилия Нигъмәтова

## Әлли-бәлли-бәү

(Бишек җыры)

Әлли-бәлли-бәү итә,
Нәнием йокыга китә.
Алтын ай аны сөя:
«Күзләреңне йом», – дия.

Әлли-бәлли-бәү итә,
Сабыем йокыга китә.
Ай кебек көлә-көлә,
Тылсымлы төшләр килә.

Әлли-бәлли-бәү итә,
Матурым йокыга китә.
Үсәр ул, олы булыр,
Инсафлы кеше булыр.

Әлли-бәлли-бәү итә,
Балам йокыга китә.
Йокла, балам, йом күзең,
Йокла, балам-йолдызым!
Әлли-бәлли-бәү...



Рәссам Фәридә Зөлкәрнәй

Салават күпере

5-6(123-124) — 2000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАТБУГАТ, ТЕЛЕРАДИОТАПШЫРУЛАР ЭШЛӘРЕ ҺӘМ МАССАКҮЛӘМ КОММУНИКАЦИЯ ЧАРАЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ
1990 елның март аеннан бирле чыга

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства информации и печати РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке.
Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде

Баш мөхәррир
**Зиннур ХӨСНИЯР**

Баш мөхәррир урынбасары
Вакыйф НУРИЕВ

Җаваплы сәркатип
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкта
Диләрә НӘҮРУЗОВА рәсемнәре

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

«Идел-пресс» полиграфия нәшрият комплексы» дәүләт унитар предприятиясе. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Производствога бирелде 2.6.2000 ел.
Басарга кул куелды 2.6.2000 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Офсет ысулы белән басылды.
Тиражы 16264 данә. Заказ Э-219.
Бәясе килешү буенча.

POINT®

Бәясе килешү буенча
Индекс 73953

# Каз бәбкәләрен саклыйм

Наилә Яхина сүзләре һәм көе.




Йөрим елга буенда,
Каз бәбкәләр янымда.
Каз бәбкәләре унбер,
Йөрмә, карга, мин сизгер.

**Кушымта:**

«Кар, кар», – димәгез,
Бәбкәләргә тимәгез.
«Кар, кар», – димәгез,
Бәбкәләргә тимәгез.

Елга буе чирәмдә,
Каз бәбкәләр тирәмдә.
Курыкмыйча йөзәләр,
Мин булганны сизәләр.

**Кушымта.**

Каз бәбкәләре озак
Судан чыкмыйча торса,
Әтиләре бик усал,
Аларны ул орыша.

**Кушымта.**

